КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 12 декабрь г.Казань № 1085

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру советы составына үзгәрешләр кертү хакында

Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 сентябрь, 639 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 364 нче; 2018 ел, 16 май, 372 нче; 2021 ел, 25 март, 168 нче; 2022 ел, 19 апрель, 368 нче; 2022 ел, 6 декабрь, 1295 нче; 2023 ел, 21 март, 302 нче; 2024 ел, 15 апрель, 255 нче; 2025 ел, 3 март, 124 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны тормышка ашыру советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Совет составыннан И.К.Сәгъдәтшинны, Р.Н.Садыйковны, А.Р.Хәйруллинны чыгарырга;

Совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Галиуллин Рөстәм Госман улын | «Татар китап нәшрияты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча) |
| Кадыйров Азат Рифгать улын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын |
| Начвин Илья Сергеевичны | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын; |

Ркаил Рафаил улы Зәйдуллин вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (Иҗади берлек), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин